ГЛАВА ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“29” октября 2019 г. — № 9

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Сикәнәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Сикәнәс авылы, Мәктәп урамы , 45 нче йорт адресы буенча урнашкан Сикәнәс авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 13 ноябрь сәгать 14.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Сикәнәс авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Сикәнәс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Секинес авылында Заречная урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, грейдлау, килешү буенча эш өчен түләү);
- Сикәнәс авылында юлларны кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башкарма комитетына Сикәнәс авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы: Л.Н.Хәбибуллин